**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 31 июлендәге 2488 номерлы карары**

**2025 елгы җиңел атлетика буенча Россия чемпионатын әзерләү һәм уздыру кысаларында Казан шәһәренең урам-юл челтәре буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында**

2025 елгы җиңел атлетика буенча Россия чемпионатын әзерләү һәм уздыру чорында иминлекне тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карарына таянып:

1. **Карар бирәм**:

1.1. 2025 елның 4 августында 0:00 сәгатьән алып 11 августында 23:00 сәгатькә кадәр, клиент төркемнәренең «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерцияле булмаган оешмасы биргән махсус рөхсәтнамәләр белән җиһазландырылган транспорт чараларыннан тыш, Казан шәһәренең Үзәк стадионы янындагы парковкада транспорт чаралары хәрәкәтен чикләүне кертергә;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыру һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплау буенча чаралар оештырырга;

1.2.2. транспорт чараларын куюны һәм аларның хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының

«Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.2.3. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм МТС.URENT) һәм велосипед («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә әлеге карарда күрсәтелгән участокларда шәхси мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю буенча эш оештырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров) Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе белән берлектә (А.И.Салихов) юлларны йөк техникасы яки таранга каршы блоклар белән ябуны оештырырга;

1.4. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерцияле булмаган оешмасына (М.С.Денисов) Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе бүлегенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән рөхсәтнамә үрнәкләрен тапшырырга;

2.2. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участогында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.3. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) әлеге урам-юл челтәре участогында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**